РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район, д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы, Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

03.04.2026 № 12

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 12.11.2025 №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 29.12.2025 №567-ФЗ Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 12.11.2025 елгы №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.12 һәм 1.13 пунктлар өстәргә:

«1.12. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Контроль органы, шулай ук контроль чаралар уздыруга җәлеп ителә торган белгечләр, экспертлар тарафыннан рәсмиләштерелә торган документлар электрон документ рәвешендә төзелә һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.

1.13. Профилактик визит үткәрү турында, кисәтү игълан итү турында, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль чараны үткәрү турында карарлар, контроль чараның, профилактик чараның актлары (шул исәптән уздыру мөмкинлеге булмау турындагы актлар), ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр контроль чараларның бердәм реестрына алар турында белешмәләр (күзәтчелек) чаралары һәм аларга имза салу кертү юлы белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән карарларны, актларны һәм күрсәтмәләрне рәсмиләштерү өчен документны аерым төзү таләп ителми.»;

1.2. 2.4 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: Контроль объекты контроль төрләренең бердәм реестрына белешмәләр кертелгәннән соң хәвеф-хәтәр категорияләренең берсенә кертелгән дип санала.»;

1.3. 3.5.3. нче пунктның «әлеге кисәтүгә карата» сүзләреннән соң «,шул исәптән бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә регион аша» сүзләре өстәргә;

1.4. 3.6.2.нче пунктның 1) пунктчасында «видео-конференц-элемтә,» сүзеннән соң «Инспектор» мобиль кушымтадан файдалану» сүзләрен өстәргә,»;

1.5. 4 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 4.11. пункт белән тулыландырырга:

«4.11. Документлар буенча тикшерелгәндә документлар контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан яисә «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин»;

1.6. 5.12.2.нче пунктның икенче абзацында ««карау,» сүзләреннән соң «, шул исәптән пилотсыз аппаратлар (системалар) кулланып» сүзләрен өстәргә;

1.7. 5.6. пунктының икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: «Шул ук вакытта 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракларда прокуратура органнары белән килештерү таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/artash адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Арташ авыл
җирлеге Башлыгы Р.И.Мөхәрләмов